# ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ

## «ТЕЛӘЧЕ» СӘНӘГАТЬ (ИНДУСТРИАЛЬ) ПАРКЫ ТУРЫНДА»

## КАРАРЫ

**Өченче чакырылышның чираттан тыш утырышы**

**2019 елның 18 феврале** **№104** **Олы Мәтәскә авылы**

Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 маендагы 136 санлы «Теләче» сәнәгать (индустриаль) паркытурында»гыкарарынаүзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131 санлы Федераль законга туры китереп, «Созидание» Идарәче компания» җаваплылыгы чикләнгән ширкәтнең тәкъдимен караганнан соң, Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 маендагы 136 санлы «Теләче» сәнәгать (индустриаль) паркы турында»гы карарына түбәндәге: «1.1.Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге территориясендә урнашкан «Теләче» сәнәгать (индустриаль) паркы территориясендәге күчемсез милек биләүче физик затларны 100% җир салымыннан азат итәргә» дигән 1.1. пунктны өстәп,үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Карарны гамәлдәге законнарга туры китереп бастырып чыгарырга.

Олы Мәтәскә авыл җирлеге башлыгы: М. А. Вәлиуллин